# МИН БЕРЕНЧЕ ЧӘЧӘКЛӘРНЕ ЭЗЛИМ

*С. Хәким сүзләре*






Мин язларны алдан көтеп алам,
Моңнарына бирелә башкаем;
Мин беренче чәчәкләрне жыйган
Урыннарга барам яз саен.

Мин беренче чәчәкләрне эзлим,
Алар, бәлки, башка төштәдер...
Беренчеләр мине сагындыра,
Беренчеләр минем истә гел.

Яз авышса, җәйнең уртасы бар,
Чәчәкләре аның ишлерәк.
Югалтуның ни икәнен белә,
Юатуны белми һич йөрәк.